СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 г.Зеленодольск № 264

2020 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымы ставкалары, тәртибе һәм түләү сроклары турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, 2013 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри түләү өчен җир салымы (алга таба - салым) билгеләргә һәм кертергә:

Түбәндәге күләмдә:

1.1. Инновацион һәм (яисә) инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы карары нигезендә төзелгән сәнәгать (индустриаль) парклары белән мәшгуль булган җир кишәрлекләренә карата 0,01 %.

1.2. Гомуми файдаланудагы 1-3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05 %.

Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен хәрби-учет белгечлекләре буенча белгечләр әзерләүне гамәлгә ашыру өчен автомәктәпнең полигоннар, автодромнар, укыту-матди базасы белән мәшгуль булган җир кишәрлекләренә карата 0,05 %.

1.3.Шифаханә-курорт оешмалары белән мәшгуль булган җир кишәрлекләренә карата 0,1 %.

1.4. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы зоналары составында булган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җир кишәрлекләренә карата 0,3%.

Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык

инфраструктурасы объектлары белән мәшгуль (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына туры килми торган җир кишәрлегенә хокукындагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата 0,3%.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән), шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләрен эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган затларга карата 0,3%;

Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборона, куркынычсызлык һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3%.

1.5. Җирле бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр биләгән торак пунктларның җирләре категориясенә керә торган җир кишәрлекләренә карата 0,403 %;

1.6. Гараж һәм автостоянкалар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;

Кунакханәләрне урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;

Сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү, автосервис объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;

Башка җир кишәрлекләре карата 1,5%;

2. Салым түләүчеләрнең законнарда каралган категорияләреннән тыш, түбәндәге категорияләрен җир салымын түләүдән азат итәргә:

- гражданнар күмү белән мәшгуль җир кишәрлекләренә карата оешмалар, учреждениеләр;

- Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, концентрацион лагерьларның балигъ булмаган тоткыннары, «Ленинград блокадасында яшәүче» билгесе булган затлар;

-резидентларның милек хокукындагы һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата, «Зеленодольск» алгарышлы социаль-икътисади үсеш территориясендә эшчәнлек алып бару турындагы килешү кысаларында, салым чорыннан соң килә торган өч салым чоры дәвамында, 2014 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 473-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, индивидуаль эшкуарга яисә юридик затка «Зеленодольск» СИҮАБТ (ТОСЭР) резиденты статусы бирелгәннәргә.

3. Кертергә:

-салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның

беренче, икенче һәм өченче кварталлары билгеләүне;

- салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче кварталдан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең тиешле процент ставкасы күләмендә, узган хисап чорыннан соң килгән айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, аванс түләүләре белән башкарыла. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килгән елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләүне;

- әлеге карарның 2 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә җир салымын түләүдән азат ителгән салым түләүчеләрдән, җир кишәрлекләрен арендага (файдалануга) биргән очракта, әлеге карарда билгеләнгән тәртиптә җир салымы алынуны.

4. Үз көчен югалткан дип таныырга:

- 2016 елның 14 ноябрендәге «2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымы ставкалары, тәртибе һәм түләү сроклары турында» 93 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары;

- 2019 елның 26 апрелендәге «2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 93 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 241 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары

- 2019 елның 08 августындагы «2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 93 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 252 номерлы карары (Зеленодольск шәһәре Советының 2019 елның 26 апрелендәге 241 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән).

5.Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басылып чыккан көн еннән бер айдан да соңга калмыйча, үз көченә керә.

6. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча даими комиссия рәисенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Мэры урынбасары** **К. С. Антипов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ